ГОРОДСКОЙ СОВЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
ШӘҺӘР СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

3 ноябрь, 2021 ел № 9/5

Татарстан Республикасы Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр кертү турында

«Татарстан Республикасы Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр кертү турында» Шәһәр Советы карары проекты буенча җәмәгать тыңлаулары нәтиҗәләрен карап тикшергәннән соң, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 28, 44 статьялары, Татарстан Республикасы Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Уставының 92, 93, 94 статьялары нигезендә

Шәһәр Советы

КАРАР бирде:

1. Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге вәкиллекле органының 2005 елның 8 декабрендәге 6/5 санлы Карары белән расланган (Шәһәр Советының 2006 елның 19 октябрендәге 15/4, 2007 елның 4 июлендәге 23/4, 2007 елның 25 декабрендәге 28/10, 2008 елның 29 февралендәге 30/7, 2009 елның 9 апрелендәге 40/6, 2009 елның 10 сентябрендәге 42/7, 2010 елның 31 мартындагы 47/7, 2010 елның 27 декабрендәге 7/6, 2011 елның 15 декабрендәге 15/7, 2012 елның 5 июлендәге 19/15, 2012 елның 20 декабрендәге 22/19, 2013 елның 29 августындагы 26/17, 2014 елның 21 февралендәге 29/17, 2014 елның 16 октябрендәге 33/17, 2015 елның 27 февралендәге 38/14, 2015 елның 23 июлендәге 41/11, 2016 елның 24 февралендәге 6/10, 2017 елның 22 февралендәге 15/10, 2017 елның 10 августындагы 18/9, 2017 елның 15 декабрендәге 21/16, 2018 елның 27 апрелендәге 24/8, 2018 елның 11 декабрендәге 28/9, 2019 елның 1 августындагы 32/13, 2019 елның 6 декабрендәге 34/14, 2020 елның 17 июнендәге 40/3, 2020 елның 29 декабрендәге 4/7, 2021 елның 27 маендагы 7/6 номерлы Карарлары редакциясендә) Татарстан Республикасы Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Уставына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1) **3 статьяның 1 өлешен** түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Муниципаль берәмлекнең тулы рәсми исеме – Татарстан Республикасы Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге шәһәр округы.

Муниципаль берәмлекнең кыскартылган исемнәре – Яр Чаллы шәһәре, Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге, Яр Чаллы шәһәре шәһәр округы.

Барлык атамалар да тигез мәгънәдә кулланыла.»;

2) **9 статьяның 1 өлешендә:**

- **4.1 пунктын** түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.1) бердәм җылылык белән тәэмин итүче оешма тарафыннан җылылык белән тәэмин итү объектларын төзү, реконструкцияләү һәм (яки) модернизацияләү чараларын башкаруга муниципаль контрольне гамәлгә ашыру;»;

- **5 пунктта** «җирле әһәмияттәге автомобиль юлларының сакланышы өчен» сүзләрен «автомобиль транспортында, шәһәр җир өсте электр транспортында һәм юл хуҗалыгында» сүзләренә алыштырырга;

- **25 пунктта** «аларның үтәлешенә контрольне гамәлгә ашыру» сүзләрен «төзекләндерү өлкәсендә шәһәр округы территориясен төзекләндерү кагыйдәләрен, шул исәптән социаль, инженерлык һәм транспорт инфраструктурасы объектларының һәм күрсәтелә торган хезмәтләрнең инвалидлар өчен уңайлы булуын тәэмин итүгә карата таләпләрне үтәү өлешендә (төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда, мәҗбүри таләпләрне (куркынычсызлык мониторингы) үтәүне күзәтү барышында ачыкланган мәҗбүри таләпләрне бозуларны бетерү турында күрсәтмә бирелергә мөмкин) муниципаль контрольне гамәлгә ашыру» сүзләренә алыштырырга;

- **30 пунктта** «куллану һәм саклау» сүзләрен «саклау һәм куллану» сүзләренә алыштырырга.

3) **19 статьяның 5 өлешен** түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5. Җәмәгать тыңлауларын, җәмәгать фикер алышуларын оештыру һәм уздыру тәртибе муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органының норматив хокукый актлары белән билгеләнә.

Муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органының норматив хокукый акты муниципаль берәмлек халкына җәмәгать тыңлаулары уздыруның вакыты һәм урыны турында алдан хәбәр итү, муниципаль хокукый акт проекты белән, шул исәптән аны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә шәһәрнең рәсми сайтында урнаштыру юлы белән, әгәр органның «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә шәһәрнең рәсми сайтында үз эшчәнлеге турында мәгълүмат урнашытырыга мөмкинлеге булмаса, «Дәүләт органнары һәм җирле үзидарә органнары эшчәнлеге турында мәгълүматтан файдалануны тәэмин итү хакында» 2009 елның 9 февралендәге 8-ФЗ номерлы Федераль закон нигезләмәләрен исәпкә алып «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасының рәсми сайтында (алга таба әлеге статьяда - рәсми сайт) урнаштыру юлы белән таныштыруны, фикер алышуга чыгарылган муниципаль хокукый акт проекты буенча муниципаль берәмлек халкы тарафыннан үз искәрмәләрен һәм тәкъдимнәрен белдерү, шул исәптән рәсми сайт аша, шәһәр халкының җәмәгать тыңлауларында катнашуын тәэмин итә торган башка чаралар, җәмәгать тыңлаулары нәтиҗәләрен, кабул ителгән карарларның дәлилләнгән нигезләнүен дә кертеп, бастырып чыгару (халыкка җиткерүне), шул исәптән аларны рәсми сайтка урнаштыру юлы белән, мөмкинлеген тәэмин итәргә тиеш.»;

4) түбәндәге эчтәлектәге **21.1 статья** өстәргә:

«21.1 статья. Гражданнар җыены

1. Гражданнар җыены торак пункт территориясе өлешендә торак пункт территориясенең әлеге өлешендә гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча үткәрелергә мөмкин.

Гражданнар җыены үткәрелә торган торак пункт территориясе өлеше чикләре, җирле әһәмияттәге мәсьәләне хәл иткәндә, торак пункт территориясенең күрсәтелгән өлешендә яшәүчеләрнең гомуми мәнфәгатьләрен критерийларыннан чыгып, Шәһәр Советы тарафыннан билгеләнә.

Гражданнар җыены үткәрелә торган торак пункт территориясенең бер өлеше чикләрен билгеләү критерийлары булып тора:

1) торак йортлар төркеменең бердәм территориаль-пространство бөтенлеге, күпфатирлы торак йорт, торак микрорайон, гражданнарның башка яшәү территориясе;

2) әлеге өлешнең 1 пунктында күрсәтелгән территориядә уннан  ким булмаган кеше яшәве.

2. Гражданнар җыенын оештыру һәм үткәрү тәртибе Шәһәр Советы тарафыннан билгеләнә.»;

5) **25 статьяның 1 өлешен** түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Җирле үзидарә органнары структурасын төзи:

а) Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Шәһәр Советы – муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы.

Урнашкан урыны: Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы, Яр Чаллы шәһәре, Хәсән Туфан проспекты, 23 йорт.

Шәһәр Уставында, башка муниципаль хокукый актларда, документларда «Татарстан Республикасы Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Шәһәр Советы» муниципаль казна учреждениесе, «Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Шәһәр Советы» МКУ, «Шәһәр Советы»,«Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Шәһәр Советы» сүзләре һәм алар нигезендә ясалган сүзтезмәләр бер мәгънәдә кулланыла.

б) Шәһәр Хакиме – муниципаль берәмлек Башлыгы – муниципаль берәмлекнең югары вазыйфаи заты;

в) Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты –  җирле администрация (муниципаль берәмлекнең башкарма-оештыручы органы).

Урнашкан урыны: Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы, Яр Чаллы шәһәре, Хәсән Туфан проспекты, 23 йорт.

Шәһәр Уставында, башка муниципаль хокукый актларда, документларда «Татарстан Республикасы Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты» муниципаль казна учреждениесе, «Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты» МКУ, «Башкарма комитет», «Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты» сүзләре һәм алар нигезендә ясалган сүзтезмәләр бер мәгънәдә кулланыла.

г) Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Контроль-хисап палатасы – муниципаль берәмлекнең контроль-хисап органы.

Урнашкан урыны: Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы, Яр Чаллы шәһәре, Хәсән Туфан проспекты, 23 йорт.

Шәһәр Уставында, башка муниципаль хокукый актларда, документларда «Татарстан Республикасы Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Контроль-

хисап палатасы» муниципаль казна учреждениесе, «Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Контроль-хисап палатасы» МКУ, «Контроль-хисап палатасы», «Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Контроль-хисап палатасы» сүзләре һәм алар нигезендә ясалган сүзтезмәләр бер мәгънәдә кулланыла.

Шәһәр Советы, Башкарма комитет, Контроль-хисап палатасы юридик зат хокукларына ия һәм федераль законнар нигезендә юридик затлар сыйфатында дәүләт теркәвенә алынырга тиеш.

Юридик зат хокукларындагы Яр Чаллы шәһәренең җирле үзидарә органнары идарә итү функцияләрен гамәлгә ашыру өчен төзелгән муниципаль казна учреждениеләре булып тора.

Җирле үзидарә органнарын юридик затлар буларак дәүләт теркәвенә алу өчен әлеге Устав һәм Шәһәр Советының юридик зат хокуклары белән тиешле җирле үзидарә органы төзү турындагы карары нигез булып тора.»;

6) **28 статьяның 2 өлешендә:**

- түбәндәге эчтәлектәге **23.1 пункт** өстәргә:

«23.1) гражданнар җыенын оештыру һәм уткәрү тәртибен билгеләү;»;

- түбәндәге эчтәлекле **77, 78, 79 пунктлар** өстәргә:

«77) муниципаль контроль төрләре турындагы нигезләмәләрне раслау;

78) Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә инициатив проектларны тәкъдим итү, кертү, фикер алышу һәм карау тәртибен раслау;

79) җирле бюджетка инициатив түләүләрне күчерүне гамәлгә ашырган затларга (шул исәптән оешмаларга) кире кайтарылырга тиешле инициатив түләүләр суммаларын исәпләү һәм кире кайтару тәртибен раслау;»;

7) **32 статьяның 2 өлешендәге 7 пунктны** түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«7) Россия Федерациясе гражданлыгын яисә чит ил гражданына җирле үзидарә органнарына сайлану хокукын бирә торган Россия Федерациясенең халыкара шартнамәсендә катнашучы чит ил гражданлыгын туктау, чит ил гражданына Россия Федерациясенең халыкара шартнамәсе нигезендә җирле үзидарә органнарына сайланырга хокук бирә торган, яисә Россия Федерациясе гражданына чит ил территориясендә даими яшәү хокукын раслаучы башка документ булган, чит ил гражданлыгы (подданный) булган, яшәүгә рөхсәткә ия булган очракта, әгәр Россия Федерациясенең халыкара шартнамәсе нигезендә башкасы каралмаган булса;»;

8) **36 статьяның 1 өлеше 8 пунктын** түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«8) Россия Федерациясе гражданлыгын яисә чит ил гражданына җирле үзидарә органнарына сайлану хокукын бирә торган Россия Федерациясенең халыкара шартнамәсендә катнашучы чит ил гражданлыгын туктау, чит ил гражданына Россия Федерациясенең халыкара шартнамәсе нигезендә җирле үзидарә органнарына сайланырга хокук бирә торган, яисә Россия Федерациясе гражданына чит ил территориясендә даими яшәү хокукын раслаучы башка документ булган, чит ил гражданлыгы (подданный) булган, яшәүгә рөхсәткә ия булган очракта, әгәр Россия Федерациясенең халыкара шартнамәсе нигезендә башкасы каралмаган булса;»;

9) **40 статьяда**:

- түбәндәге эчтәлектәге **4.4 өлеш** өстәргә:

«4.4.Башкарма комитет Җитәкчесе шәһәр Хакименә язма рәвештә Россия Федерациясе гражданлыгын яисә чит ил гражданына җирле үзидарә органнарына сайлану хокукын бирә торган Россия Федерациясенең халыкара шартнамәсендә катнашучы чит ил гражданлыгын туктату турында, яисә чит ил гражданлыгын (подданный булу) алу яисә яшәүгә рөхсәт алу, яки Россия Федерациясе гражданының чит ил территориясендә даими яшәү хокукын раслаучы яки Россия Федерациясенең халыкара шартнамәсе нигезендә җирле үзидарә органнарына сайланырга хокукка ия булган чит ил гражданының даими яшәү хокукын раслаучы башка документның гамәлдән чыгуы турында бу хакта билгеле булган көндә, Россия Федерациясе гражданлыгы яисә чит ил гражданлыгы туктатылу яки чит ил гражданлыгын (подданство), яшәүгә рөхсәт яки әлеге пунктта каралган башка документ алу көненән башлап биш көннән дә соңга калмый хәбәр итәргә тиеш.»;

**- 5 өлешнең 9 пунктын** түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«9) Россия Федерациясе гражданлыгын яисә чит ил гражданына җирле үзидарә органнарына сайлану хокукын бирә торган Россия Федерациясенең халыкара шартнамәсендә катнашучы чит ил гражданлыгын туктау, чит ил гражданына Россия Федерациясенең халыкара шартнамәсе нигезендә җирле үзидарә органнарына сайланырга хокук бирә торган, яисә Россия Федерациясе гражданына чит ил территориясендә даими яшәү хокукын раслаучы башка документ булган, чит ил гражданлыгы (подданный) булган, яшәүгә рөхсәткә ия булган очракта, әгәр Россия Федерациясенең халыкара шартнамәсе нигезендә башкасы каралмаган булса;»;

10) **41 статьяда:**

**- 3 өлештә**

**3 пунктны** көчен югалткан дип танырга;

түбәндәге эчтәлектәге **10 пункт** өстәргә:

«10) җирле әһәмияттәге дәвалау-савыктыру урыннарын һәм курортларны булдыру, үстерү һәм саклауны тәэмин итү, шулай ук җирле әһәмияттәге махсус саклана торган табигать территорияләрен саклау һәм файдалану өлкәсендә муниципаль контрольне гамәлгә ашыру;»;

**- 4 өлешнең 13.7 пунктында** «җирле үзидарә органы инициативасы буенча» сүзләрен «Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексында каралган очракларда» сүзләренә алыштырырга**;**

**- 9 өлештә**:

**9.4.1 пунктын** түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«9.4.1) җылылык белән тәэмин итү объектларын төзү, реконструкцияләү һәм (яки) модернизацияләү буенча бердәм җылылык белән тәэмин итүче оешма тарафыннан йөкләмәләрнең үтәлешенә муниципаль контрольне гамәлгә ашыру;»;

**14 пунктта** «шәһәр территориясен төзекләндерү кагыйдәләре үтәлешенә контрольне гамәлгә ашыру» сүзләрен «төзекләндерү өлкәсендә шәһәр округы территориясен төзекләндерү кагыйдәләрен үтәү, шул исәптән социаль, инженерлык һәм транспорт инфраструктурасы объектларының һәм күрсәтелә торган хезмәтләрнең инвалидлар өчен уңайлы булуын тәэмин итүгә карата таләпләрне үтәү тора (төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда, мәҗбүри таләпләрне (куркынычсызлык мониторингы) үтәүне күзәтү барышында

ачыкланган мәҗбүри таләпләрне бозуларны бетерү турында күрсәтмә бирелергә мөмкин) муниципаль контрольне гамәлгә ашыру» сүзләренә алыштырырга;

**19 пунктны** түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«19) шәһәр округы чикләрендә автомобиль транспортында, шәһәр җир өсте электр транспортында һәм юл хуҗалыгында муниципаль контрольне гамәлгә ашыру;»;

- **12 өлештә** түбәндәге эчтәлектәге **11 пункт** өстәргә:

11) шәһәр территориясендә эпидемиягә, эпизоотиягә, эпифитотиягә каршы чараларны гамәлгә ашыруда катнашу;»;

- **16 өлешне** түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«16. Яшьләр сәясәте өлкәсендә:

1) яшьләр сәясәтен тормышка ашыруда катнашу;

2) шәһәр округы территориясендә яшьләрнең хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен тәэмин итү һәм яклау чараларын эшләү һәм тормышка ашыру;

3) шәһәр округы территориясендә яшьләр белән эшләү чараларын оештыру һәм уздыру;

4) яшьләр сәясәтен тормышка ашыруның төп юнәлешләре буенча муниципаль программаларны эшләү һәм тормышка ашыру;

5) шәһәр округы территориясендә яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыру мониторингын оештыру һәм гамәлгә ашыру;

6) яшьләр хокукларын гамәлгә ашыру өлкәсендә федераль законнарда билгеләнгән башка вәкаләтләр.»;

- **18.2 өлешне** яңа редакциядә бәян итәргә:

«18.2. Башкарма комитет муниципаль контрольне гамәлгә ашыруга вәкаләтле орган булып тора.

Муниципаль контроль төрләре реестры, Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан расланган контроль төрләренең бердәм реестрын формалаштыру һәм алып бару кагыйдәләре нигезендә, Башкарма комитет тарафыннан алып барыла.

Муниципаль контроль өлкәсендә Башкарма комитет вәкаләтләренә керә:

1) муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда дәүләт контроле (күзәтчелеге), муниципаль контроль өлкәсендә бердәм дәүләт сәясәтен гамәлгә ашыруда катнашу;

2) муниципаль берәмлек территориясендә муниципаль контрольне оештыру һәм гамәлгә ашыру;

3) «Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында» 2020 елның 31 июлендәге 248-ФЗ номерлы Федераль закон, башка федераль законнар нигезендә башка вәкаләтләр.»;

11) **44 статьяны** түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«44 статья. Контроль-хисап палатасының төп вәкаләтләре

1. Контроль-хисап палатасы түбәндәге төп вәкаләтләрне башкара:

1) җирле бюджет средстволарын, шулай ук Россия Федерациясе законнарында каралган очракларда башка средстволарны куллануның законлылыгына һәм нәтиҗәлелегенә контрольне оештыру һәм гамәлгә ашыру;

2) җирле бюджет проектларына экспертиза ясау, аның күрсәткечләренең нигезле булуын тикшерү һәм анализлау;

3) җирле бюджет үтәлеше турында еллык хисапны тышкы тикшерү;

4) «Дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләрне сатып алу өлкәсендә контракт системасы турында» 2013 елның 5 апрелендәге 44-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә товарлар, эшләр һәм хезмәт күрсәтүләрне сатып алу өлкәсендә аудит үткәрү;

5) муниципаль милекне формалаштыру, аның белән идарә итү һәм мондый милек белән эш итүнең нәтиҗәлелеген бәяләү һәм мондый милекне формалаштыруның, идарә итүнең һәм аның белән эш итүнең билгеләнгән тәртибен (интеллектуаль эшчәнлек нәтиҗәләренә карата аерым хокукларны да кертеп) үтәүне тикшереп тору;

6) муниципаль берәмлек бюджеты средстволары исәбеннән салым һәм башка ташламалар һәм өстенлекләр, бюджет кредитлары бирүнең нәтиҗәлелеген бәяләү, шулай ук юридик затлар һәм шәхси эшмәкәрләр тарафыннан муниципаль берәмлек бюджеты һәм муниципаль милектәге мөлкәт хисабына башкарыла торган килешүләр буенча яисә үтәүнең башка ысуллары буенча йөкләмәне үтәүне тәэмин итүнең законлылыгын бәяләү;

7) муниципаль хокукый актлар проектларына муниципаль берәмлекнең чыгым йөкләмәләренә кагылышлы өлешендә экспертиза ясау, муниципаль берәмлек бюджеты керемнәрен үзгәртүгә китерә торган муниципаль хокукый актлар проектларына, шулай ук муниципаль программаларга (муниципаль программа проектларына) экспертиза ясау;

8) муниципаль берәмлектә бюджет процессына анализ ясау һәм мониторинг үткәрү, шул исәптән бюджет процессында ачыкланган кимчелекләрне бетерү һәм Россия Федерациясе бюджет законнарын камилләштерү буенча тәкъдимнәр әзерләү;

9) агымдагы финанс елында муниципаль берәмлек бюджеты үтәлешенә һәм үтәлешне оештыруга оператив анализ ясау һәм контрольдә тоту, муниципаль берәмлек бюджетының үтәлеше барышы турында, уздырылган контроль һәм эксперт-аналитик чараларның нәтиҗәләре турында Шәһәр Советына һәм шәһәр Хакименә квартал саен мәгълүмат тапшыру;

10) муниципаль эчке һәм тышкы бурычны тикшереп торуны гамәлгә ашыру;

11) муниципаль берәмлекнең стратегик планлаштыру документларында каралган муниципаль берәмлекнең социаль-икътисадый үсеше максатларына ирешүнең гамәлгә ашырылуын, куркынычларын һәм нәтиҗәләрен Контроль-хисап палатасы компетенциясе чикләрендә бәяләү;

12) коррупциягә каршы чараларда вәкаләтләр чикләрендә катнашу;

13) федераль законнарда, Татарстан Республикасы законнарында, шәһәр уставында, муниципаль берәмлекнең Шәһәр Советының норматив хокукый актларында билгеләнгән тышкы муниципаль финанс контроле өлкәсендәге башка вәкаләтләр.»;

12) **48.1 статьяны** түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«48.1 статья Яр Чаллы шәһәре җирле үзидарә органнарында, муниципаль органнарда муниципаль вазыйфалар биләүче затлар

1. Муниципаль вазыйфаларны биләүче затлар булып Шәһәр Советы депутатлары, шәһәр Хакиме, муниөипалҗ берәмлек башлыгы урынбасары, Контроль-хисап палатасы рәисе, рәис урынбасары, аудиторлары, Сайлау комиссиясе рәисе тора.

2. Муниципаль вазыйфаларны даими нигездә биләүче затларга «Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы депутаты, җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзасы, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи заты вәкаләтләрен гамәлгә ашыру гарантияләре турында» 2009 елның 12 февралендәге 15-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законында каралган гарантияләр бирелә.

3. Муниципаль вазыйфаларны даими нигездә биләүче затларга шәһәр Уставының 48 статьясындагы 7 өлешендә каралган өстәмә гарантияләр бирелә, шулай ук муниципаль вазыйфа биләүче затның вазыйфаи бурычларын үтәвенә бәйле рәвештә сәламәтлегенә һәм мөлкәтенә зыян килгән очракта, мәҗбүри дәүләт иминияте гарантияләнә. Өстәмә гарантияләр бирү тәртибе һәм шартлары Шәһәр Советы карары белән билгеләнә.

4. Муниципаль вазыйфаларны биләүче затларга вәкаләтләрне гамәлгә ашыру гарантияләре җирле бюджет средстволары исәбеннән финанслана.»;

13) **50 статьяның 5.1 өлешен** түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5.1 Шәһәр Советының җирле салымнарны һәм җыемнарны билгели, үзгәртә, юкка чыгара торган норматив хокукый актлар проектларыннан, гадәттән тыш хәлләр режимнары гамәлдә булган чорда табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрне бетерү максатларында эшләнгән норматив хокукый актлар проектларыннан тыш, эшмәкәрлек һәм башка икътисадый эшчәнлек субъектлары өчен элек билгеләнгән таләпләрне үзгәртә торган яки яңа таләпләр билгели торган, инвестиция эшчәнлеге субъектлары өчен йөкләмәләр билгели торган, муниципаль норматив хокукый актлар проектлары Татарстан Республикасы Законы нигезендә муниципаль норматив хокукый актларда билгеләнгән тәртиптә җирле үзидарә органнары тарафыннан үткәрелә торган җайга салу йогынтысына бәяләнергә тиеш.

Муниципаль норматив хокукый актлар проектларының җайга салу йогынтысын бәяләү эшмәкәрлек һәм башка икътисадый эшчәнлек субъектлары өчен артык вазыйфалар, тыюлар һәм чикләүләр кертә торган яисә аларны кертүгә этәрә торган нигезләмәләрне, шулай ук эшмәкәрлек һәм башка икътисадый эшчәнлек субъектларының һәм шәһәр бюджетының нигезсез чыгымнары барлыкка килүгә ярдәм итә торган нигезләмәләрне ачыклау максатларында үткәрелә.»;

14) **54 статьяның 5 өлешен** көчен югалткан дип танырга;

15) **71 статьяның 2 өлешендә** «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1 статьясындагы 1 өлешенең 4.3 пунктында каралган очракта, гражданнар җыенында» сүзләрен өстәргә.

16) **84 статьяның 2 өлешен** көчен югалткан дип танырга.

2. Әлеге Карар, үз көченә керү гамәлдәге законнар белән башка вакытта каралган аерым нигезләмәләрдән тыш, матбугатта рәсми басылган көннән үз көченә керә.

3. Яр Чаллы шәһәре Хакиме Н.Г. Мәһдиевка әлеге Карарны гамәлдәге законнарда билгеләнгән тәртиптә дәүләт теркәвенә тапшырырга.

4. Әлеге Карар үтәлешен контрольдә тотуны Шәһәр Советының регламент, хокук тәртибе һәм халык иминлеген тәэмин итү мәсьәләләре буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Шәһәр Хакиме Н.Г. Мәһдиев

Россия Федерациясе Юстиция министрлыгының Татарстан Республикасы буенча идарәсе тарафыннан 2021 елның 17 ноябрендә теркәлде. Дәүләт теркәве номеры RU 163020002021003